**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ГЛАВА**
**Чубар-Абдулловского сельского поселения Азнакаевского муниципального района**

ул. Советская, д. 81 , село Чубар-Абдуллово
Азнакаевского муниципального района, 423323
Тел. (факс) (85592)38-7-37
Chabd.Azn@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул авыл җирлеге Советы**
**БАШЛЫГЫ**

Совет урамы, 81, Чубар-Абдул авылы
Азнакай муниципаль районы, 4233237
Тел. (факс) (85592) 38-7-37
Chab.Azn@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**10 октябрь 2022 ел** **№4**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул авыл җирлегенең Буралы торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларынкертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

06.10.2003 ел №131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Закон һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Чубар-Абдул авыл җирлеге Уставы нигезендә карар чыгарам:

1.Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районыны Чубар-Абдул авыл җирлеге Буралы торак пунктында 2022 елның 22 октяберендә 10 сәгать 00 минутта үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының беренче этабын билгеләргә Джалиль урамы 1 йорттан 73 йортка кадәр, Пионер урамы 1 йорттан 17 йортка кадәр

2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул авыл җирлеге Чубар-Абдул авылында теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен 2022 елның 22 октяберендә 11сәгать 00 минутта үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының икенче этабын билгеләргә: Октябрь урамы 1 йорттан 79 йортка кадәр, Мәктәп урамы 1 йорттан 21 йортка кадәр.

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез, 2023 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль Чубар-Абдул авыл җирлеге Буралы торак пункт территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм анда катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, 350 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- бәйрәм чараларын оештыру һәм үткәрү (Яңа ел, Сабантуй, Халыкара өлкәннәр көне);
- урам утларын, яктырткычларны, махсус җиһазларны сатып алу, энергия саклаучы лампаларны урнаштыру, килешү буенча эш өчен түләү:
- Янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча чаралар (янгын сүндерү җиһазлары һәм материаллары сатып алу)
- Октябрьская урамы буенча, Җәлил урамы буенча гравий капламы белән юллар салу (ташу, вак таш җәю, килешү буенча эш өчен түләү).

« РИЗА» «КАРШЫ».

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы, Буралы авылы, Октябрь ур., 34 йорт адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

5. Әлеге карар ул халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Башлык: Н. Ә. Фәтхетдинов